# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№1** **12.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге составына керүче,
Чалпы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 12 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2020 елда, Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Чалпы авылында Ленин, Яшьләр, Садовая, Новая, Гагарин, Казан урамнары буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Чалпы авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- Чалпы авылы территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю урыннарын чистарту;
- Чалпы авылы зиратлары өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;
- Чалпы авылында янгын сүндергечләр, янгын сундерү ранецлары, янгынга каршы инвентарь сатып алу;
- Чалпы юлларын кардан чистарту;
- Чалпы авылы территориясен җәйге чорда чабу;
- Чалпы авылында коры агачлар, куакларны кисү;
- Чалпы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Чалпы авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (койма урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Чалпы авылында һәйкәл (мемориаль такталар) урнаштыру;
- Чалпы авылында урам исемнәре язылган табличкалар әзерләү;
- Чалпы авылындагы гидротехник корылма янында «су коенырга ярамый» дигән табличкалар ясау, урнаштыру;
- Чалпы авылында «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 576 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 317 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 317 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; җыенда катнашучы 0 кеше «Юк» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге составына керүче Чалпы авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2020 елда, Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Чалпы авылында Ленин, Яшьләр, Садовая, Новая, Гагарин, Казан урамнары буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Чалпы авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;

- Чалпы авылы зиратлары өчен җиһазлар һәм инвентарь (генератор, отбойный чүкеч) сатып алу;

- Чалпы авылында янгын сүндергечләр, янгын сундерү ранецлары, янгынга каршы инвентарь сатып алу;

- Чалпы юлларын кардан чистарту;

- Чалпы авылы территориясен җәйге чорда чабу;

- Чалпы авылында коры агачлар, куакларны кисү;

- Чалпы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Чалпы авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (койма урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү) ;

- Чалпы авылында һәйкәл (мемориаль такталар) урнаштыру;

- Чалпы авылында урам исемнәре язылган табличкалар әзерләү;

- Чалпы авылындагы гидротехник корылма янында «су коенырга ярамый» дигән табличкалар ясау, урнаштыру;

- Чалпы авылында «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленин урамы, 130 йорт; ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы мәктәп бинасында мәгълүмат стенды, ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы,Үзәк урам, Чалпы амбулаториясе бинасында үзәк мәгълүмат стенды, ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Үзәк урам, 39 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чалпы авыл җирлеге Башлыгы: А.М. Мөхәмәтшин